ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23 май, 2019 ел № 31/10

Шәһәр Советының “Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында” карар проекты буенча җәмәгать тыңлаулары турында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 28 маддәсенә, 2017 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 463-ФЗ санлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 19, 28 маддәләре, Шәһәр Советының 2008 елның 25 сентябрендәге 34/8 санлы Карары белән расланган гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезнамәгә нигезләнеп,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. «Шәһәр Советының 2017 елның 24 октябрендәге 20/8 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Шәһәр Советыкарары проектын (алга таба – Шәһәр Советы карары проекты) хупларга һәм 1 нче кушымта нигезендә җәмәгать тыңлауларына чыгарырга.

2. Карар проекты буенча җәмәгать тыңлаулары (алга таба - җәмәгать тыңлаулары) үткәрү көнен 2019 елның 05 июленә, үткәрү вакытын 14:00 сәгатькә тәгаенларга, үткәрү урыны итеп Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты бинасында (Х.Туфан проспекты, 23 йорт) 400 залны билгеләргә.

3. Җәмәгать тыңлаулары үткәрү буенча комиссия составын 2 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Шәһәр Советының 2008 елның 25 сентябрендәге 34/8 санлы Карары белән расланган гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе

турында Нигезнамәгә (Шәһәр Советының 2012 елның 20 апрелендәге 18/20 санлы Карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 1 пунктта «шәһәр территориясен төзекләндерү кагыйдәләре проекты буенча» сүзләрен «шәһәр территориясен төзекләндерү кагыйдәләре проекты буенча һәм аларга үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проект буенча» сүзләренә алыштырырга;

2) 10 пунктта «шәһәр территориясен төзекләндерү кагыйдәләре проекты буенча» сүзләрен «шәһәр территориясен төзекләндерү кагыйдәләре проекты буенча һәм аларга үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проект буенча» сүзләренә алыштырырга.

5. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының
31/10 Карарына
1 нче кушымта
23 май, 2019 ел

Проект

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
Шәһәр Советы

КАРАРЫ

,2019 ел №

Шәһәр Советының 2017 елның 24
октябрендәге 20/8 санлы Карары белән
расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге территориясен төзекләндерү
Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 28 маддәсенә, 2017 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 463-ФЗ санлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсенә нигезләнеп,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2017 елның 24 октябрендәге 20/8 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә (Шәһәр Советының 2018 елның 10 августындагы 26/11, 2019 елның 25 февралендәге 30/6 санлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3 бүлек. Гомуми таләпләр

7. Шәһәрнең бөтен территориясе һәм анда урнашкан барлык биналар (шул исәптән торак йортлар) һәм корылмалар (алга таба - биналар, корылмалар) төзекләндерелергә, каралырга һәм җыештырылырга тиеш.

8. Торак мохитнең, урамнар һәм юлларның, мәдәни-көнкүреш хезмәте күрсәтү объектларының төзекләндерү обьектларын проектлаганда, төзекләндергәндә һәм карап тотканда халыкның аз

хәрәкәтләнүче төркемнәре өчен мохитнең уңайлы булуын, шул исәптән әлеге объектларны халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәре өчен элементлар һәм техник чаралар белән тәэмин итүне күздә тотарга кирәк.

Халыкның аз мобильле төркемнәре хәрәкәтен тәэмин итүче техник чаралар һәм җиһазларны проектлаштыру, төзү, урнаштыру заказчы тарафыннан расланган проект документлары нигезендә төзелеш барышында гамәлгә ашырыла.

9. Гомуми файдалану территорияләрен, шул исәптән мәйданчыклар, урамнар, юллар, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары, яр буе, скверлар, бульварлар, пляжлар, башка объектлар урнашкан җир участокларын карап тотуны һәм җыештыруны оештыру мәсьәләләрен вәкаләтле органнар үз вәкаләтләре чикләрендә гамәлгә ашыра.

9.1. Физик һәм юридик затлар, оештыру-хокукый формасына карамастан, милек хокукында, аренда һәм башка әйбер хокукында яисә йөкләмәле хокукта (алга таба - җир участоклары хокукына ия затлар) файдаланган җир участокларын һәм янәшә территорияне, шулай ук биналар, корылмалар территорияләрен мөстәкыйль рәвештә яисә үз хисапларына махсус оешмаларны җәлеп итү юлы белән карап тотуны һәм җыюны гамәлгә ашыралар.

Әгәр бинага, корылмага милек хокукында, башка әйбер хокукында яки мәҗбүри хокукта берничә зат ия булса булса, җыештырылырга тиешле территория милек хокукындагы өлешкә яки күчемсез милек объектындагы башка хокукка пропорциональ рәвештә билгеләнә.

Җир участогы территориясендә төрле затлар ия булган биналар, корылмалар булса, территорияне карап тоту һәм җыештыру чикләре якларның үзара килешүе нигезендә билгеләнә ала.

Килешү булмаганда, җыештырылырга тиешле территория барлык милекчеләр яки биналарның, корылмаларның хуҗалары (кулланучылары) арасында тигез өлешләрдә билгеләнә.

Физик яки юридик зат карамагында булган җир участогы билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелмәгән очракта, биләмә, шулай ук якын-тирә территория факттагы чикләре буенча җыештырылырга тиеш.

Әгәр бинага, корылмага милек яки башка әйбер хокукында яйсә мәҗбүри хокукта берничә зат ия булса, фасадны карап тоту яклар килешүе белән билгеләнә ала.

Килешү булмаганда, фасадны тоту милек хокукындагы өлешкә яки күчемсез милек объектына башка хокукка пропорциональ рәвештә башкарыла.

9.2. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм җыештыру муниципаль заказны урнаштыру нәтиҗәләре буенча әлеге эш төрләрен үткәрүгә конкурсออткан махсуслаштырылган оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

9.3. Аерым трамвай юлларын, трамвай тукталышларын карап тоту һәм җыештыру эксплуатацияләүче оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

9.4. Шәһәр территориясендә уза торган тимер юллар, читләштерү полосасы чикләрендә, тимер юлны аркылы чыгу урыннары һәм

җәяүлеләр кичү юллары әлеге корылмалардан файдаланучы оешмалар карап тота.

9.5. Күп фатирлы йортларның һәм алар янындагы территорияләрнең карап тоту һәм җыештыру күп фатирлы йортлар белән идарә итү ысулларының берсенә туры китереп башкарыла: торак милекчеләре ширкәте яки торак кооперативы яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары, идарәче оешма, күп фатирлы йортта гомуми милекне карап тоту һәм ремонтлау эшләрен башкаручы затлар тарафыннан, - әлеге йорт милекчеләре тарафыннан турыдан - туры идарә итү юлы белән (алга таба-идарәче оешмалар).

9.6. Шәхси торак йортлар һәм тирә-юнь территорияләрен карап тоту һәм җыештыру мондый йортларның милекчеләре (йорттан вакытлыча файдаланучылар) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

9.7. Яшелләндерү һәм төзекләндерү элементларын карап тотуны гамәлгә ашыралар:

1) бирелгән җир участогы чикләрендә – җир кишәрлегенең милекчеләре яисә башка хокук ияләре;

2) гомуми файдаланудагы яшелләндерелгән территорияләр чикләрендә –муниципаль заказны урнаштыру нәтиҗәләре буенча әлеге эшләр башкаруга конкурста откан вәкаләтле орган яйсә махсуслаштырылган оешма;

3) чикләнгән яшелләндерү территорияләре (предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр) һәм махсус билгеләнештәге (санитар зоналар, су саклау зоналары, зиратлар, питомниклар) чикләрендә – әлеге объектларның хуҗалары;

4) йорт яны территорияләре чикләрендә – күп фатирлы йортларда торак биналарның милекчеләре яки идарәче оешмалар;

5) җир өсте коммуникацияләренең саклау зоналарында, шул исәптән электр челтәрләре, яктырту челтәрләре, радио линияләрендә – әлеге коммуникацияләрнең хуҗалары;

6) җир асты коммуникацияләренең сак зоналарында (әгәр урнаштыру рөхсәт ителгән булса) – күрсәтелгән коммуникацияләрнең хуҗалары.

9.8. Урам һәм юллардан җир асты һәм өслек суларын җыю, су бүлеп бирү өчен билгеләнгән кюветларны, торбаларны, дренаж корылмаларын, яңгыр канализациясе коллекторларын һәм яңгыр сулары коеларын чистарту аларны эксплуатацияләүче оешмалар тарафыннан башкарыла.

9.9. Диспетчерлык пунктлары территорияләрен, шәһәр җәмәгать транспортының борылу мәйданчыкларын карап тоту һәм җыештыру шәһәр пассажир транспортын эксплуатацияләүче оешмалар тарафыннан башкарыла.

9.10. Җәмәгать транспортын көтү павильоннарын карап тоту һәм җыештыру вәкаләтле территориаль органнар тарафыннан муниципаль заказны урнаштыру нәтиҗәләре буенча әлеге эш төрләрен үткәрүгә конкурста откан махсус оешмалар белән килешүләр нигезендә тәэмин ителә.

9.11. Җәмәгать бәдрәфләрен урнаштыру һәм карап тоту тәртибе гамәлдәге законнар, санитар кагыйдәләр һәм нормалар нигезендә билгеләнә.

Бәдрәфләрнең санитар һәм техник торышын аларның милекчеләре, хуҗалары, арендаторлар, яки аларга хезмәт күрсәтүче махсус оешмалар тәэмин итә.

9.12. Шәһәр территориясен карап тоту һәм җыештыру чикләре физик һәм юридик затлар тарафыннан бирелгән җир участогы чикләре (милектәге җир участогы билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелмәгән булса, җир участогының факттагы чиге буенча) һәм бина һәм корылма милекчеләренең әлеге Кагыйдәләрнең 3.1 бүлеге нигезендә якын-тирә территорияләрне төзекләндерүдә катнашу тәртибе нигезендә билгеләнә.

9.13. Вәкаләтле органнар билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә шәһәр территориясен, шул исәптән гомуми файдаланудагы территорияләрне, карап тоту һәм җыештыру эшләренең үтәлешен тикшереп торалар.

9.14. Муниципаль берәмлекнең гомуми кулланудагы территорияләрендә түбәндәгеләр тыела:

1) территорияләрне тимер-томыр, төзелеш һәм көнкүреш чүп-чары, шлак һәм башка калдыклар белән чүпләү, ягулык-майлау материаллары, нефть продуктлары белән пычрату, калдыклардан чүп өеме өю;

2) махсус билгеләнгән урыннардан һәм калдыкларны җыю контейнерларыннан тыш башка урыннарга калдыклар һәм чүп-чар тутыру;

3) билгеләнгән тәртипне бозып, стационар сәүдә обьектлары, ял итү өлкәсендә хезмәт күрсәтү сферасы обьектлары (халыкның ялын оештыру һәм күңел ачу аттракционнары, кабартылган батутлар, роликлар, велосипедлар прокаты һәм башка шундый объектлар) урнаштыру;

4) яшел утыртмаларда (агачларда, куаклыкларда, су торбаларында, урамдагы коймаларда, асфальт һәм плитәләрдә һәм башка каралмаган урыннарда) реклама һәм мәгълүмат материаллары урнаштыру;

5) махсус билгеләнгән урыннардан тыш башка җирдә автотранспорт чараларын юу һәм чистарту;

6) бу максатлар өчен махсус җиһазландырылмаган машиналарда, юлларны пычратудан саклаучы брезент һәм башка каплау чарасын кулланмыйча, коела торган, тузансыман йөкләр, эремәләр, корыган яфрак, калдыклар, сыек йөкләр ташу;

7) стационар булмаган сәүдә обьектларын рөхсәтсез урнаштыру;

8) җир эшләрен рөхсәт язуы (ордер) булмыйча башкару;

9) туфрак, чүп-чар, калдыклар, кар, бозны бу максатка каралмаган урыннарга чыгару;

10) гамәлдәге законнарны бозып, төзү материалларын урамнарда, тротуарларда, газоннарда тоту, квартал эчендәге юлларны һәм йорт яны юлларын ябу;

11) газоннар, тротуарлар, урамнар, мәйданнар, ишегалды территорияләре, парклар, скверлар һәм башка җәмәгать урыннарында тәмәке төпчекләре, кәгазь, чүп ташлау;

12) бакча диваннарының, эскәмияләренең артына утыру, урналарны, урамны яктыртучы фонарьларны, башка кече архитектура формаларын пычрату, аларга зыян салу яки вату;

13) себерелгән чүпне һәм көнкүреш калдыкларын кое капкачлары, яңгыр сулары канализациясенең су агып төшә торган рәшәткәләре өстенә, улак һәм кюветларга ташлау;

14) чүп, корыган яфрак һәм үләнне, буш савытларны, җитештерү калдыкларын, каты коммуналь калдыкларны яндыру, учак ягу, шул исәптән, янгынга каршы чаралары булмаган (ябык савытлар һәм янгын сүндерү чаралары) предприятие һәм шәхси хуҗалыклар эчендә;

15) тиеш булмаган урыннарда урам сәүдәсе оештыру;

16) фасадларны рөхсәтсез үзгәртү, барлык типтагы гаражларны урнаштыру, билгеләнмәген урыннарда тышкы мәгълүмат чараларын, кече архитектура формаларын урнаштыру;

17) яшел утыртмаларны сындыру, бозу, юк итү, кәүсәләрне рөхсәтсез кисү, агачларга кадак кагу, гамаклар һәм таганнар, кер баулары элү;

18) газоннарга зыян китерү һәм аларны юк итү.

19) транспорт чараларын яшелләндерелгән территорияләрдә, балалар һәм спорт мәйданчыкларында, хайваннарны йөртү мәйданчыкларында, шулай ук йорт яны территориясендә урнашкан хуҗалык мәйданчыкларында урнаштырыру;

20) инженерлык-техник тәэмин итү челтәрен җир асты вариантында һәм проект документларыннан башка төзү;

21) бу максатлар өчен билгеләнмәгән җир участокларында транспорт чаралары кую урыннарын җиһазландыру;

22) бу максатлар өчен билгеләнмәгән җир участокларында стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру.»;

2) түбәндәге эчтәлектәге 3.1 бүлеген өстәргә:

«3.1. бүлек. Җир участоклары, биналар, корылмалар (аларда торак биләүчеләр) милекчеләренең яки башка хокукка ия булучыларның якын-тирә территорияләрне төзекләндерүдә катнашу тәртибе

9.15. Шәһәр территорияләренең тиешле санитар торышын тәэмин итү, шәһәр территориясен пычратудан саклау буенча чараларны тормышка ашыру максатларында хуҗалык итүче субъектлар һәм физик затларга әйләнә-тирә территорияләр беркетелә.

9.16. Территорияләрне (җир участокларын) җыештыру, чистарту һәм санитар карап тоту буенча эшләр башкару бурычлары гамәлдәге җир законнары, торак урыннар территорияләрен карап тотуның санитария кагыйдәләре нигезендә, әгәр закон яки килешү белән башкача каралмаган булса, физик һәм юридик затларга алдагы тәртиптә йөкләнә:

9.16.1. идарәче оешмалар – күп фатирлы йортларның йорт яны территориясе, шулай ук күп фатирлы йортның төп фасады ягыннан 10 метр радиуста яки урамның машиналар йөри торган өлешенә кадәр (объект юл буенда урнашкан очракта) җир территориясе;

9.16.2. күп фатирлы торак йортларда торак булмаган мәйданнарны эксплуатацияләүче затлар - биналарның бөтен озынлыгы дәвамында,

киңлеге10 м яки юл бордюрына кадәр (объект юл буенда урнашкан очракта) территорияне, идарәче оешма белән килешү булмаган очракта;

9.16.3. социаль өлкә учреждениеләре (мәктәпләр, мәктәпкәчә учреждениеләр, мәдәният, сәламәтлек саклау, физкультура һәм спорт учреждениеләре) - бирелгән җир участогы чикләрендәге территорияләр, шулай ук учреждениенең төп фасады каршында 10 метр радиустагы территория яисә урамның машиналар йөрү өлешенә кадәр (юл буенда объект урнашкан очракта) 10 м радиуста территория;

9.16.4. барлык милек формасындагы сәнәгать предприятиеләре һәм оешмалар - 15 м радиустагы якын-тирә территорияләр, аларга керү юллары, 15 м радиустагы тротуарлар;

9.16.5. төзүче (подрядчы) - гамәлдәге төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре нигезендә, 15 м радиуста төзелеш мәйданнары һәм 15 м радиуста аларга керү юллары;

9.16.6. торак йортлар хуҗалары - бирелгән җир участогы чикләрендә (җир участогы билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелмәгән очракта, факттагы җир участогы чиге буенча) һәм 5 м, яки йорт янынннан урамның машиналар йөри торган өлешенә кадәр территория (объект юл буенда урнашкан очракта);

9.16.7. стационар булмаган объектлар (лотоклар, киосклар, павильоннар һәм башка стационар булмаган сәүдә объектлары) һәм сезонлы кафелар хуҗалары - объектны урнаштыру өчен бирелгән җир участогы территориясе һәм аның чигеннән 10 м ераклыкта һәм урамның машиналар йөри торган өлешенә кадәр (объект юл буенда урнашкан очракта) территория;

9.16.8. сәүдә һәм җәмәгать туклануы оешмалары (базарлар, кибетләр, рестораннар, кафелар) - бирелгән җир участогы чикләрендә территорияләр һәм участок чикләреннән 15 м радиуста якын-тирә территория (объект юл буенда урнашкан очракта);

9.16.9. бина, корылмаларның милекчеләре яки башка хокукка ия булучылар - бина периметры, корылма яки бирелгән җир участогы чикләре һәм участок чикләреннән 15 м радиуста якын-тирә территория (объект юл буенда урнашкан очракта);

9.16.10. автомобиль юлларының юл буе полосалары чикләрендә урнашкан ягулык салу станцияләре, сәүдә һәм җәмәгать туклануы объектлары - бирелгән җир участогы чикләрендә һәм участок чикләреннән 50 м радиуста якын-тирә территория һәм урамның машиналар йөри торган өлешенә кадәр;

9.16.11. гараж кооперативлары - бирелгән җир участогы чикләрендә, участок чикләреннән 15 м радиуста урнашкан һәм урамның машиналар йөри торган өлешенә кадәр, аларга керү юлларына кадәр территорияләр;

9.16.12. гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек коммерцияле булмаган берләшмәләре - бирелгән җир участогы территориясе һәм участок чикләреннән 15 м радиустагы һәм урамның машиналар йөри торган өлешенә кадәр (объект юл буенда урнашкан очракта);

9.16.13. җирләү урыннары - бирелгән җир участогы чикләрендә һәм участок чикләреннән 15 м радиустагы территория;

9.16.14. автотранспорт чараларын озак һәм кыска вакытлы саклау тукталышлары хуҗалары - бирелгән җир участогы чикләрендәге һәм аның янәшәсендәге территория, җир кишәрлегенең тышкы чигеннән 10 м ераклыкта һәм урамның машиналар йөри торган өлешенә кадәр (объект юл буенда урнашкан очракта);

9.16.15. коммуналь билгеләнештәге корылмалар урнашкан оешмалар-җир участогы чигеннән 10 метр радиуста;

9.16.16. автоматлаштырылган режимда (хезмәт күрсәтү персоналыннан башка) эшләүче инженер корылмалары урнашкан предприятиеләр-җир участогы чигеннән 10 м радиуста;

9.16.17. хезмәт күрсәтүче оешма- ике яклап төзелеш алып барылган урамнарда биләгән участок озынлыгы буенча, киңлеге буенча-магистраль тротуарга кадәр, тротуар булмаганда-урамның бордюр полосасына кадәр;

9.16.18. хезмәт күрсәтүче оешма - бер яклап төзелеш алып барылган урамнарда биләгән участок озынлыгы буенча, киңлеге буенча-урамның бөтен киңлегенә, капма-каршы тротуарны да кертеп, һәм тротуар ның аргы ягында 10 м;

9.16.19. хезмәт күрсәтүче оешма - җир өсте юлы периметры буенча 5 м радиуста җир асты һәм җир өсте кичү юллары, баскыч яны һәм кичү юллары өчен;

9.16.20. хезмәт күрсәтүче оешма – трамвай юллары өчен кырый рельстан ике яктан да 5 метр;

9.16.21. хезмәт күрсәтүче оешма – тимер юллар өчен шәһәр эчендәге читләштерү юлары чикләрендә, юл янындагы авышлыклыр, юл аша чыгу юллары һәм алар янәшәсендәге өлешләр өчен ике якка да 5 метр.

Якындагы территория гомуми файдаланудагы юл белән кисешкән очракта, якындагы территориянең зурлыгы юл бордюры яки тротуар бордюры белән кисешкәнчегә кадәр билгеләнә. Юл бордюры булмаганда якындагы территориянең зурлыгы гомуми файдаланудагы юл белән турыдан-туры кисешкәнчегә кадәр билгеләнә.

Факттагы зурлыгы әлеге Кагыйдәләр белән билгеләнгән зурлыктан ким булган ике һәм аннан да күбрәк объектларның территорияләре кисешкәндә, аларның зурлыгы объектлар арасындагы араның яртысы күләмендә билгеләнә.

Территорияләрнең мәйданы кисешкәндә, тирә-юньдәге территорияләр чикләре объектлардан тигез ераклыкта билгеләнә.»

3) түбәндәге эчтәлектәге 36.1, 36.2 пунктларын өстәргә:

«36.1. Каты коммуналь калдыкларны җыю урыннарын (мәйданчыкларын) булдыру Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты һәм Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсенең Татарстан Республикасы (Татарстан) Яр Чаллы шәһәре, Актаныш, Тукай, Мөслим, Минзәлә районнары буенча территориаль бүлеге белән килешү нигезендә башкарыла.

36.2. Яр Чаллы шәһәре территориясендә каты коммуналь калдыклар җыю урыннары (мәйданчыклары) реестры һәм схемасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан кәгазьдә

һәм электрон рәвештә алып барыла һәм Интернет челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштырыла.»;

4) түбәндәге эчтәлектәге 207.1 пунктын өстәргә:

«207.1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә Сосновский балтырганының таралуына юл куймау максатыннан, физик һәм юридик затлар милек хокукындагы җир участокларында һәм якынтирә территорияләрдә әлеге чүп үләненең үстермәскә тиеш.».

2. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының
31/10 Карарына
2 нче кушымта
23 май, 2019 ел

Шәһәр Советының 2017 елның 24 октябрендәге 20/08 Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар проекты буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрү комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| 1. Зуев Илья Сергеевич | – Комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесенең Беренче урынбасары; |
| 2. Ситдыйков Салават Әнәс улы | –Комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы |
| 3. Альменеева Эльвира Емельяновна | – Комиссиянең җаваплы секретаре, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы урынбасары, торак-коммуналь хуҗалыгы һәм төзекләндерү бүлеге башлыгы; |
| Комиссия әгъзалары: | |
| 4. Әхмәтҗанов Ленар Илдар улы | – Башкарма комитетның хокук идарәсе башлыгы; |
| 5. Галимов Искәндәр Нургаллләм улы | – Башкарма комитетның Үзәк районы Хакимияте Башлыгы; |
| 6. Гарипов Наил Габбас улы | – Татарстан Республикасы табигый ресурслар һәм экология министрлыгының Кама буе территориаль идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| 7. Госманов Фәнис Васил улы | – Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге административ комиссиясе рәисе урынбасары; |
| 8. Исхаков Илмир Зөфәр улы | – Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 9. Кислов Александр Иванович | – Башкарма комитетның Комсомол районы Хакимияте Башлыгы; |

| | | |
|---|---|---|
| 10 | Николаев Олег Юрьевич | – Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясе рәисе; |
| 11. | Насыйбуллин Айрат Ахмай улы | – «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы административ-техник инспекция идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы; |
| 12. | Харисов Винер Хәмит улы | – Башкарма комитетының Автозавод районы Хакимияте Башлыгы. |